ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЙОМРАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

15 февраль 2019 ел №158

“Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә аерым башкарма орган сыйфатында катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге Советы карар итә:

1.2017 елның 7 августындагы 77 номерлы Иске Йомралы авыл җирлеге Советы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Иске Йомралы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә аерым башкарма орган сыйфатында катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пунктында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары " сүзләрен төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске Йомралы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Йомралы авыл җирлеге башлыгы Р.А.Муратов